Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАРЫ

2014 елның 18 апреле 71№

Әлки муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру буенча комиссия турында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә нигезендә Әлки муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Расларга:

Әлки муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру буенча комиссия турында нигезләмә (1 нче кушымта);

Әлки муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составы (2 нче кушымта).

2. 2009 елның 8 июнендәге «Әлки муниципаль районының идарә кадрлары резервын формалаштыру комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 32 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы Ф.М. Дәүләтшин

Әлки муниципаль районы
Советының
2014 елның 18 апрелендәге
71 номерлы карарына 1 нче
кушымта

**Әлки муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру буенча комиссия турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә белән вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия даими эшләүче орган булып тора һәм үз эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервын төзү турында килешүләр нигезендә вәкаләтләр тапшыру турында төзелгән башка муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Комиссиянең персональ һәм сан составы Әлки муниципаль районы Советы тарафыннан төзелә һәм раслана.

## II. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре

4. Комиссиянең төп бурычлары:

1) Әлки муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыруны һәм алардан нәтиҗәле файдалануны оештыру;

2) Әлки муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең кадрлар резервын формалаштыру буенча җирле үзидарә органнары (сайлау комиссияләре аппаратлары) эшчәнлеген координацияләү.

5. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

1) Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турындагы Нигезләмә нигезендә кадрлар резервына кертү өчен дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү (алга таба - кадрлар резервы турындагы нигезләмә);

2) һәр дәгъвачының баллы бәяләү системасына нигезләнгән дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алу методикасын раслау;

3) Әлки муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының (сайлау комиссияләре аппаратының) вакантлы вазыйфалар биләү өчен дәгъва кылуда җирле үзидарә органнарының (сайлау комиссияләре аппаратының) ихтималын ел саен бәяләү.

## III. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

6. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Әлки муниципаль районы, Әлки муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан (сайлау комиссияләре аппаратыннан) һәм оешмаларыннан Комиссия эшчәнлеген башкару өчен кирәкле мәгълүматны сорарга һәм алырга;

2) үз утырышларына граждан дәгъва кылган вазыйфа буенча эшчәнлек өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча экспертларның фикерен тыңларга;

3) гражданнарга тест үткәрүне оештыру һәм аларның һәркайсына психологик портретын төзү өчен дәүләт мәгариф учреждениеләре белән килешү төзергә.

7. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен комиссия үтәргә тиеш:

1) Әлки муниципаль районы составына керүче гражданнарга һәм җирле үзидарә органнарына (сайлау комиссияләре аппаратларына) кадрлар резервына кертүгә, конкурс сайлап алу нәтиҗәләренә һәм гражданнарны кадрлар резервыннан төшереп калдыруга конкурс нигезендә сайлап алу уздыру турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә;

2) дәгъвачыларның кадрлар резервына алдан исемлеген төзү максатларында Әлки муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары (сайлау комиссияләре аппаратлары) тарафыннан тәкъдим ителгән документларны һәм материалларны карарга һәм эксперт бәяләмәсен үткәрергә;

3) үзе тәкъдим иткән анкетада күрсәтелгән шәхси белешмәләрдән файдалануга дәгъва кылучыдан язма ризалык алырга;

4) конкурс сайлап алуның беренче этабын уздыру йомгаклары буенча кадрлар резервы турындагы Нигезләмәдә каралган карарларның берсен кабул итәргә һәм дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алуның икенче этабын уздырганчы аның турында язма рәвештә һәм җирле үзидарәнең тиешле органнары (сайлау комиссияләре аппаратлары) хәбәр итәргә;

5) һәр дәгъвачының йомгаклау баллын билгеләү белән конкурста сайлап алуның икенче этабында бәяләмә үткәрергә;

6) конкурс сайлавының икенче этабында катнашучы дәгъвачыларны кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә;

7) кадрлар резервына кертелгән гражданнарны әзерләү буенча гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашырырга;

8) Әлки муниципаль районы составына керүче җирле үзидарә органнарыннан (сайлау комиссияләре аппаратларыннан), Әлки муниципаль районы составына керүче җирлекләрдән ел саен тапшырыла торган

мәгълүматларны гомумиләштерергә һәм анализларга, кадрлар резервына кертелгән гражданнарны әзерләүнең шәхси планнарын үтәү турында хисаплар бирергә;

9) кадрлар резервы турындагы Нигезләмәдә каралган очракларда гражданны кадрлар резервыннан чыгару турында карар кабул итәргә;

10) Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар исемлеген урнаштыруны тәэмин итәргә.

## IV. Комиссиянең эш тәртибе

8. Комиссия утырышлары вакантлы вазыйфаларны биләү өчен дәгъва кылуда Әлки муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары (сайлау комиссияләре аппараты) ихтыяҗы ихтималын ел саен уздырыла торган Комиссиянең эш планы нигезендә уздырыла. Кирәк була калса, комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырыла ала.

9. Комиссия рәисе, секретаре һәм Комиссия әгъзаларыннан (алга таба - комиссия әгъзалары) тора.

10. Комиссия рәисе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

2) Комиссиянең эш планын раслый, Комиссиянең чираттан тыш утырышын чакыру турында карар кабул итә;

3) Комиссия утырышларын үткәрү урынын һәм вакытын билгели;

4) Комиссия утырышларында рәислек итә;

5) утырышлар, хатлар һәм Комиссия карары беркетмәләренә имза сала;

6) үз компетенциясе чикләрендә Комиссия кабул иткән карарларның үтәлешен тикшереп тора.

11. Комиссия секретаре түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Комиссия эше планнарын әзерләүне тәэмин итә;

2) Комиссия утырышын уздыру урыны һәм вакыты турында Комиссия әгъзаларына мәгълүмат бирә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

3) Комиссиягә керә торган документларны һәм материалларны кабул итә, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә, аларны Комиссия утырышына карау өчен әзерли;

4) Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

5) конкурс сайлап алуының икенче этабында претендентлар җыйган балларны санауны гамәлгә ашыра;

5) Комиссиянең утырышлар беркетмәләрен, хатларны һәм Комиссия карарын рәсмиләштерә.

12. Комиссиянең башка әгъзалары түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар:

1) Комиссия утырышларында, карарлар проектларын әзерләүдә катнашалар;

2) Комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3) Комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр;

4) тиешле белешмә-мәгълүмат материаллары белән танышалар.

13. Комиссия әгъзалары саны 7 кешене тәшкил итә (так сан тәшкил итәргә тиеш).

14. Комиссия утырышы, әгәр анда аның барлык әгъзалары катнашса, хокуклы дип санала.

15. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән Комиссия әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

16. Тавыш бирү нәтиҗәләре һәм конкурс сайлавын дәгъвачыларның һәркайсының йомгаклау баллары утырыш беркетмәсендә теркәлә һәм Комиссия карары белән рәсмиләштерелә.

17. Комиссия утырышы карары һәм беркетмәсе рәисе тарафыннан имзалана.

18. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү, утырышлар беркетмәләрен һәм Комиссия карарларын саклау буенча оештыру-техник эшне башкару бурычлары Әлки муниципаль районы Советы аппараты (яисә Әлки муниципаль районы башкарма комитеты) кадрлар хезмәтенә йөкләнә.

19. Комиссия әгъзалары аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша.

Әлки муниципаль районы
Советының
2014 елның 18 апрелендәге
71 номерлы карарына 2 нче
кушымта

**Әлки муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе:**
Билалов Рәшит Әбрар улы - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы урынбасары.

**Комиссия рәисе урынбасары:**
Камалов Фәнис Флер улы - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе.

**Комиссия секретаре:**
Гатауллина Чулпан Ришат кызы-Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигы урынбасары.

**Комиссиянең башка әгъзалары:**
Нуруллина Эльвира Галиевна - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе (килешү буенча);
Габидуллин Илгиз Ислам улы - Әлки муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча);
Гарипова Рузия Морат кызы - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының юридик бүлек башлыгы;
Даутов Вайыс Разак улы - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы.